**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ИШТИРӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«29» декабрь 2025 ел Иштирәк авылы № 5/1

Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хәрби исәпкә алу буенча белгечләрнең хезмәтенә түләү турында нигезләмә»гә үзгәрешләр кертү раслау хакында

«Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр турында» РФ Хөкүмәтенең 2006 елның 29 апрелендәге 258 номерлы карары, «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында » 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 66 статьясы, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 144 статьясы, «Россия Федерациясе Кораллы Көчләре хәрби частьләре һәм оешмаларының граждан персоналы (хезмәткәрләре) хезмәтенә түләү системасы турында» Россия Федерациясе Оборона министрының 2024 елның 30 сентябрендәге 595 номерлы боерыгы, авыл җирлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хәрби исәп буенча белгечләргә хезмәт өчен түләү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2025 елның 5 декабрендәге 4/5 номерлы карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хәрби-исәп хезмәткәренең вазыйфаи окладының күләмен бүлекчә башлыгы ярдәмчесе окладына тиңләштерелгән окладтан «Россия Федерациясе Кораллы Көчләре хәрби частьләре һәм оешмаларының граждан персоналы (хезмәткәрләре) хезмәтенә түләү системасы турында» РФ оборона министрының 2024 елның 30 сентябрендәге 595 номерлы боерыгы нигезендә билгеләргә.

Вазыйфа оклады күләме, сум
Бүлекчә башлыгы ярдәмчесе 11030,00.

Хезмәт хакына карата «Россия Федерациясе Кораллы Көчләре хәрби частьләре һәм оешмаларының граждан персоналы (хезмәткәрләре) хезмәтенә түләү системасы турында» РФ оборона министрының 2024 елның 30 сентябрендәге 595 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы өчен 1,15 тәшкил иткән коэффициент кулланыла.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар, финанслар һәм икътисад сәясәт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы А.П. Васильева